| | |
|---|---|
| СОВЕТ РУССКО-АЗЕЛЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ РУС ӘҖИЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**2024 елның 22 мае** Рус Әҗиле ав. **№161**

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Рус Әҗиле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең вәкаләтләренең бер өлешен торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә тапшыру турында

2003 елның 6 октябрендәге 131 нче Федераль закон нигезендә «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында», Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Рус Әҗиле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы белән Зеленодольск муниципаль районының Рус Әҗиле авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы муниципаль берәмлегенә торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Зеленодольск авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең вәкаләтләренең бер өлешен тапшырырга:

Рус Әҗиле авыл җирлеге муниципаль берәмлекнең Рус Әҗиле авылында мәктәп автобус маршруты өчен тукталыш төзү.

2. Рус Әҗиле авыл җирлеге башкарма комитетына Яшел Үзән муниципаль районы Башкарма комитеты белән торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләсе буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турында килешү төзергә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында игълан итәргә (http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр порталының Интернет челтәрендә

(http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук Рус Әҗиле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча: Рус Әҗиле авылы, Центральная урамы, 1йорт (җирлек администрациясе бинасы), Карәшәм авылы, Новая урамы, 27 йорт (мәдәният йорты бинасы) урнаштырырга.

**Рус Әҗиле авыл җирлеге башлыгы**
**Совет рәисе** **Г.Ф.Семахина**

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН ЗЕЛЕНОДОЛЬСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН ОГРН 1021606754036 СОВЕТ РУССКО-АЗЕЛЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ РУС ӘҖӘЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ ИНН 1620001239 КПП 162001001 ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ